РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**09.12.2024** Кукмара ш. **№ 703**

2024 финанс елында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан 2024 һәм 2025 финанс елларында сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм:**

1. 2024 финанс елында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан 2024 һәм 2025 финанс елларында сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибен кушымтага ярашлы расларга.
2. Әлеге карарны ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Ч.Г. Хәнәфинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**

Башкарма комитеты җитәкчесенең 2024 елның 09 декабрендәге 703 номерлы карарына кушымта

2024 финанс елында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан 2024 һәм 2025 финанс елларында сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге тәртип 2024 финанс елында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), эшчәнлеген бер календарь елдан кимрәк башкаручы, милек рәвешләренә карамастан, агросәнәгать комплексы оешмаларына 2024 һәм 2025 финанс елларында сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә, өстәлгән бәягә салым түләү чыгымнарын киметеп субсидияләр (алга таба – субсидия) бирүнең шартларын, максатларын һәм тәртибен билгели.

2. Субсидия Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең (алга таба – Башкарма комитет) «2024 – 2026 елларга Кукмара муниципаль районы авыл хуҗалыгын үстерү» район муниципаль программасын раслау турында» 2024 елның 03 декабрендәге 695 номерлы карары белән расланган «2024 – 2026 елларга Кукмара муниципаль районы авыл хуҗалыгын үстерү» район муниципаль программасы кысаларында бирелә.

3. Субсидия бирү шартлары:

сатып алына торган сөт юнәлешендәге нәселле таналар хакының кимендә 40 процентын субсидия алучының үз акчалары исәбеннән гариза бирү датасыннан да соңга калмыйча түләү;

сатып алына торган сөт юнәлешендәге нәселле таналар өчен уңышлы орлыкландыру яше 16 айдан да артмаска тиеш;

субсидия алучының субсидия алучы белән (устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашындагы дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, устав (җыелма) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашындагы коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата Башкарма комитеты тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга карата төзелгән шартнамәләр нигезендә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүгә карата акча алучы затларның килешүе;

алынган акчалар хисабына чит ил валютасын сатып алуны тыю, Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алганда башкарыла торган операцияләрдән тыш.

Субсидия бирү бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләренең билгеләнгән тәртиптә бюджет акчаларын баш бүлүчегә – әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет акчаларын алучы буларак Башкарма комитетка җиткерелгән лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында https://kukmor.tatarstan.ru (алга таба – рәсми сайт) урнаштырыла.

5. Субсидия бирү ысулы чыгымнарны финанс белән тәэмин итүдән гыйбарәт.

6. Субсидия алучыларны сайлап алу (алга таба – сайлап алу) ысулы булып, тәкъдимнәр (гаризалар) (алга таба – гариза) соратып алу – сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керү чиратлыгыннан чыгып сайлап алу тора.

7. Башкарма комитет рәсми сайтта сайлап алуны уздыру турында белдерүне сайлап алуны уздыру срогы башланган көнгә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү вакыты;

гаризалар бирә башлау яисә кабул итүне тәмамлау даталары, ул сайлап алуны уздыру турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 нчы календарь көннән иртәрәк була алмый;

Башкарма комитетның атамалары, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 18 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсе;

әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

гаризалар бирү тәртибе һәм әлеге Тәртипнең 10 пунктының икенче абзацы нигезендә гаризаларның формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

гаризаларны кире алу тәртибе, гаризаларны кире кайтару тәртибе, шул исәптән гаризаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгеләп, гаризаларга үзгәрешләр кертү тәртибе;

әлеге Тәртипнең 11 һәм 12 пунктлары нигезендә гаризаларны карау кагыйдәләре;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны уздыру турында белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, моның башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) субсидия бирү турындагы килешүгә имза салырга тиешле вакыт (алга таба – килешү);

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән читләшкән дип тану шартлары;

сайлап алу нәтиҗәләрен рәсми сайтта урнаштыру датасы, ул сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннең иртәгәсенең 14 нче календарь көненнән дә соңга калмаска тиеш.

8. Субсидия алучыларны сайлап алу критерийлары:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып бару;

дәүләт нәсел регистрында теркәлү турында таныклыгы булган нәсел заводларыннан һәм нәсел репродукторларыннан яисә 2025 елның 1 ноябренә кадәр срокка китерү графигы белән импорт буенча китерелә торган сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга шартнамә булу;

9. Гариза бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага сайлап алуда катнашучы түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

шул исәптән аның теркәлү урыны булып Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган исемлегенә кертелгән дәүләт яисә территория тора торган (алга таба – офшор компанияләр) чит ил юридик заты булып саналмый, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләрнең турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аша) катнашу өлеше тулаем алганда 25 проценттан артып киткән россия юридик заты булып саналмый (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса). Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләгәндә, офшор компанияләренең Россия Федерациясендә оештырылган сатуларда акцияләре әйләнештә булган гавами акционер җәмгыятьләр капиталында турыдан-туры һәм (яисә) читләтеп катнашуы (шул исәптән халыкара компания статусы белән),шулай ук офшор компанияләренең күрсәтелгән гавами акционер җәмгыятьләр капиталында катнашу аша гамәлгә ашырылган башка Россия юридик затлары капиталында читләтеп катнашуы исәпкә алынмый;

Экстремистлык эшчәнлегенә яисә террорчылыкка катнашы булулары турында белешмәләре булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО Уставының VII бүлегендә, БМО Иминлек советында яисә БМО Иминлек Советының махсус төзелгән карарларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында төзелә торган вәкаләтләрдә булмый, террорчылык оешмалары һәм террористлар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә юк;

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының башка норматив хокукый актлары нигезендә әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән

максатларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан акча алмый;

«Чит ил йогынтысындагы затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып саналмый;

сайлап алуда катнашучының бердәм салым хисабында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы юк яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

сайлап алуда катнашучының Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетына бүтән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча срогы чыккан (җайга салынмаган) башка бурычы юк;

юридик зат булган сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булган юридик затка, башка юридик затка кушылу рәвешендәге үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмый, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатып торылмаган, ә шәхси эшмәкәр булган сайлап алуда катнашучы шәхси эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмаган.

10. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен, сайлап алуда катнашучы Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыра:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турындагы мәгълүматны үз эченә алган, түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча гариза, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы бирә торган гариза турында мәгълүматны һәм сайлап алуда катнашучы турында сайлап алуга бәйле башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгы, шулай ук шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (физик зат өчен);

юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан яисә шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан билгеләнгән тәртиптә таныкланган өземтә йә юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан яисә шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтыннан гариза бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән белешмәләр (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, Башкарма комитет аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан Салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү бурычларын үтәү турында салым органының гариза

бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән, «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү бурычларын үтәве турында белешмә формасын һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» Федераль салым хезмәтенең 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча белешмәсе (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, Башкарма комитет күрсәтелгән мәгълүматны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмәсе;

сатып алына торган сөт юнәлешендәге нәселле таналар хакының кимендә 40 процентын түләүне раслый торган банк өземтәләренең һәм түләү йөкләмәләренең (аванс түләвен дә кертеп) күчермәләре;

2024 һәм 2025 финанс елларында сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга шартнамәләрнең күчермәләре, сөт юнәлешендәге нәселле таналар кайтару буенча шартнамә яклары белән килештерелгән графикны теркәп;

сатып алына торган сөт юнәлешендәге токымлы таналар өчен түләү счетларының күчермәләре;

хисап финанс елы өчен статистик хисаплылык формалаштыру өчен терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

Тапшырылган документларның күчермәләре сайлап алуда катнашучылар тарафыннан таныклана.

Гаризадагы мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен, сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

Сайлап алуда катнашучы гаризасын сайлап алу тәмамланганчы теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда, сайлап алуда катнашучы гаризалар бирү өчен билгеләнгән вакытта кабат гариза бирергә хокуклы, бу вакытта гариза кергән көнне чират тәртибендә теркәлә.

11. Башкарма комитет:

сайлап алуны уздыру турында белдерүдә билгеләнгән сайлап алуны үткәрү вакыты дәвамында гаризаларны, аларны кабул итү датасын һәм вакытын күрсәтеп, кергән көнне терки;

сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән гаризаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көн эчендә тапшырылган документларны сайлап алуны уздыру турында белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәү мәсьәләсенә карый, сайлап алу нәтиҗәләре турында әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча реестр төзи һәм сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү турында йә гаризаны кире кагу турында карар кабул итә;

сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләгән көннең 14 нче календарь көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» челтәрендә рәсми сайтта сайлап алу нәтиҗәләре турында түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган мәгълүмат урнаштыра:

гаризаларны карау датасы, вакыты һәм урыны;

гаризалары каралган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

гаризалары кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында, гаризаларны кире кагу сәбәпләре, шул исәптән сайлап алуны уздыру турында белдерүнең мондый гаризалар туры килми торган нигезләмәләре күрсәтелгән мәгълүмат;

килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

12. Гаризаларны карау һәм бәяләү стадиясендә гаризаны кире кагу өчен нигезләр:

сайлап алу критерийларына һәм әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган гаризаның һәм документларның сайлап алуда катнашучыларның сайлап алуны уздыру турында белдерүдә билгеләнгән гаризаларына таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучының гариза бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яисә) вакыттан соң гариза бирүе;

сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән, хокукый актта каралган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

сайлап алуда катнашучыларның әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимиты бетү.

13. Сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат рәсми сайтта урнаштырылган көннән алып биш эш көне эчендә Башкарма комитет субсидияләр алучылар белән әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча килешү төзи;

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

а) субсидиянең максатчан билгеләнеше, финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелә торган чыгымнарны җибәрү, субсидия күләме һәм аны күчерү вакыты;

б) субсидия бирүне тәмамлауның төгәл датасы һәм нәтиҗәләренең ахыргы кыйммәте (нәтиҗәсенә конкрет санлы характеристика);

в) субсидия алучының Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән өстәмә хисапларны тапшыру рәвеше һәм вакыты;

г) алынган акчалар хисабына чит ил валютасын сатып алуны тыю, Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алганда башкарыла торган операцияләрдән тыш;

д) субсидияне Башкарма комитет бюджетына кире кайтару тәртибе;

е) субсидия алучының субсидия алучы белән (устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашындагы дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, устав (җыелма) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашындагы коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата Башкарма комитеты тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга карата төзелгән шартнамәләр нигезендә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүгә карата акча алучы затларның килешүе;

ж) килешүнең яңа шартларын килештерү турында һәм килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары Башкарма комитетка кимегән очракта, яңа шартлар буенча килешүгә ирешмәгәндә, килешүне өзү турында шарт.

Кирәк булганда, Башкарма комитет субсидия алучылар белән килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү дә төзи.

Юридик зат булган субсидия алучыны берләштерү, кушу яисә үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп оештырганда, килешүдә хокук варисы булган юридик затны күрсәтеп, йөкләмәдә затны алыштыру өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәрешләр кертелә.

«Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында» 2003 елның 11 июнендәге 74-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә үз хокукларын башка гражданга тапшыручы, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 23 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацы нигезендә крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы буларак эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси эшмәкәр булган субсидия алучының эшчәнлеге туктатылганда, килешүдә хокук варисы булган башка затны күрсәтеп, йөкләмәдә затны алыштыру өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәрешләр кертелә.

14. Субсидия алучы, әлеге Тәртипнең 13 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә кул куюын тәэмин итмәгән очракта, килешү төзүдән читләшкән дип таныла.

15. Башкарма комитет

Башкарма комитет, сайлап алуны уздыру турында белдерүдә килешүләр төзүне тәмамлау срогы билгеләнгән көннән алып бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидия алучыларга субсидия бирү турында яисә субсидия бирүне

кире кагу турында карар кабул итә, ул Башкарма Комитет боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы фактын ачыклау.

16. Башкарма комитет субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидия алучыларга ачылган исәп-хисап яисә корреспондент счетларына акча күчерә.

17. Субсидия бирелә торган чыгымнарны тоту, өстәлгән бәягә салым түләү чыгымнарын исәпкә кертмәгәндә, сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алудан гыйбарәт.

18. Сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (W) (сумнарда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = C \times S,$$

монда:

C – субсидия алучы тарафыннан сатып алына торган сөт юнәлешендәге нәселле таналар бәясе, өстәлгән бәягә салым түләү чыгымнарын исәпкә кертмәгәндә, сум;

S – сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидия ставкасы, сатып алу бәясенең 60 проценты исәбеннән, ләкин бер башка исәпләгәндә 75,0 мең сумнан артык түгел.

Сөт юнәлешендәге токымлы таналар кайтару шартнамәсе нигезендә чит ил валютасында түләү каралган очракта, сатып алына торган сөт юнәлешендәге токымлы таналарның баш саны бәясе Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан чит ил валютасына билгеләнгән курс буенча Россия сумнарында таможня декларациясендә күрсәтелгән бәядән исәпләнә.

19. Субсидия алучы әлеге Тәртип нигезендә субсидия бирелгән сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алу чыгымнарын Татарстан Республикасы бюджетыннан каплауга гариза бирергә хокуклы түгел.

20. Субсидия бирү нәтиҗәсе:

а) сатып алу датасына, субсидияләрдән файдаланып сатып алынган сөт юнәлешендәге нәселле таналар саны;

б) 2025 елның 31 декабренә эре мөгезле терлекләрнең маточный баш санын саклап калуны тәэмин итү, 2024 елның 1 гыйнварына булган мөгезле терлекнең баш санына карата.

Субсидиядән файдаланып сатып алынган сөт юнәлешендәге токымлы таналарның баш саны 2024 елның 1 гыйнварына булган маточный мөгезле эре терлекләрнең баш саныннан күбрәк булган очракта, 2025 елның 31 декабренә маточный мөгезле эре терлекләрнең баш саны сатып алынган сөт юнәлешендәге токымлы таналар башыннан кимрәк булмаска тиеш;

21. Субсидия алучы Башкарма комитетка түбәндәгеләрне тапшыра:

финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 нче числосыннан да соңга калмыйча, еллык хисап - 2025 елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, килешүгә кушымта итеп бирелә торган форма буенча хисап;

субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешү турында килешүгә кушымта итеп бирелә торган форма буенча хисаплар:

әлеге Тәртипнең 20 пунктының «а» пунктчасында билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешү турында, хисапка түбәндәге документларны теркәп, 2026 елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча:

Башкарма комитет тарафыннан расланган форма буенча нәсел таныклыклары (сертификатлар) реестры һәм сатып алынган сөт юнәлешендәге нәселле таналар өчен нәсел таныклыклары (сертификатлар) күчермәләре;

сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алу ае дәвамында фермада терлек һәм кош-корт движениесе турында хуҗалык эчендәге айлык хисап күчермәсе;

сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуны раслый торган накладной яисә көтү ведомосте күчермәсе;

сатып алынган сөт юнәлешендәге нәселле таналар өчен «Меркурий» дәүләт мәгълүмат системасыннан алынган, бергә теркәлә торган ветеринария документларының (ветеринария таныклыгы, ветеринария белешмәсе) күчермәләре;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге дәүләт ветеринария берләшмәсе биргән субсидия алучының терлекләрне карантиннан чыгару актының күчермәсе;

сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуны һәм түләүне раслый торган банк өземтәсенең һәм түләү йөкләмәсенең (аванс түләвен дә кертеп), накладной яисә көтү ведомостенең күчермәсе;

әлеге Тәртипнең 20 пунктының «б» пунктчасында билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешү турында, 2026 елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча:

Микропредпринимательлек субъекты булган субсидия алучы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24

июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, килешүгә кушымта итеп бирелгән форма буенча елга бер тапкыр, 2026 елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Башкарма комитетка субсидия бирү нәтиҗәсе кыйммәтенә ирешү турында хисап тапшыра.

22. Башкарма комитет субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турындагы хисапны күрсәтелгән хисап бирелгән көннән алып күп дигәндә 60 эш көнендә тикшерә.

23. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе кыйммәтенә ирешү һәм Субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларга (контроль нокта) мониторинг Башкарма комитет тарафыннан нәтиҗәләргә ирешү мониторингын уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

Микропредпринимательлек субъекты булган субсидия алучыга субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү мониторингы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә елга бер мәртәбә үткәрелә.

24. Башкарма комитет субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә үтәвен тикшерә.

Дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

25. Хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калдыклары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты кеременә хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча кайтарылырга тиеш, күрсәтелгән акчаларга ихтыяҗ булу-булмавы турында, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы белән килештереп, Башкарма комитет тарафыннан карар кабул ителгән очраклардан тыш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган акчаларны әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга куллану ихтыяҗы булган очракта, субсидия алучы, хисап елыннан соң килә торган елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча, Башкарма комитетка мондый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат тапшыра.

Башкарма комитет субсидия алучыдан әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат алган көннән соң 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы белән килештереп, бюджет законнары нигезендә субсидия алучының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган калган өлешен тотуга ихтыяҗы булу-булмавы турында карар кабул итә.

Башкарма комитет субсидия алучының агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калган өлешен тотуга ихтыяҗы булу турында карар кабул иткән очракта, Башкарма комитет белән субсидия

алучы арасында мондый карар кабул ителгән көннән алып календарь көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә өстәмә килешү төзелә.

26. Бирелгән субсидия Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты керемена Башкарма комитетның тиешле хәбәрнамәсен алган көннән календарь көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия биргәндә билгеләнгән шартларны, шул исәптән Башкарма комитет һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартларны бозу ачыкланган очракларда;

әгәр субсидия алучы субсидия бирү нәтиҗәсенең килешүдә билгеләнгән күрсәткечләренә ирешмәгән очракта, субсидия алучы субсидия акчаларын формула буенча билгеләнә торган күләмдә (Vвозврат) кире кайтара:

$$V_{возврата} = (V_{субсидии} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

Vсубсидия – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – түбәндәге формула буенча билгеләнә торган, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – субсидия алучының хисап датасына субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән күрсәткече;

S – субсидия алучыга килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең планлы күрсәткече.

Субсидия акчаларын кире кайтару күләмен исәпләгәндә, коэффициентның субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган уңай күрсәткечләре генә файдаланыла.

27. Башкарма комитет субсидия акчаларын килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә кире кайтару турында, вакытын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп хәбәрнамә җибәрә, почта аша аны тапшыру турында хәбәрнамә белән.

Әлеге Тәртипнең 26 пунктында күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты керемена ирекле кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә 30 көн эчендә Башкарма комитет тарафыннан мәҗбүри рәвештә түләтелергә тиеш.

28. Бюджет акчаларын куллануны контрольдә тотуны Башкарма комитет гамәлгә ашыра.

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең ______ елның _____________ _____ номерлы карары белән расланган 2024 финанс елында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан 2024 һәм 2025 финанс елларында сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Башкарма комитет җитәкчесенә
__________________________________
__

кемнән: __________________________
(оешманың исеме)
__________________________________
_______________________ исеменнән,
(оешма җитәкчесенең вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме, соңгысы – булган очракта)
__________________________________
___________ нигезендә эш итүче

Субсидия алу хокукына (чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә)
сайлап алуда катнашуга
гариза

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибе нигезендә Субсидия алу хокукына сайлап алуда катнашу өчен, түбәндәге мәгълүматларны һәм документларны тапшырам:

Оешма исеме: ______________________________

ИНН/КПП: ______________________________

Исәп-хисап счеты: _________________ _____________________________

Банк исеме: __________________ _________________________

Корр. счет: _____________________________

БИК ______________ _________________________

ОКТМО (муниципаль берәмлеккә кадәр): _________

Юридик затны теркәү адресы: ___________________________________

Урнашу урыны адресы: ________________________________________________

Җитәкченең элемтә телефоны: ______________ _________________

E-mail: ________________________

Шулай ук 2024 елның ________________ ______________________________

(көн, ай)

_________________________________________________________________

(сайлап алуда катнашучы исеме)

**түбәндәге таләпләргә туры килә:**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып бара һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булган юридик затка, башка юридик затка кушылу рәвешендәге үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмый, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатып торылмаган, ә сайлап алуда катнашучы – шәхси эшмәкәр – шәхси эшмәкәр сыйфатында эшчәнлеген туктатмаган;

шул исәптән аның теркәлү урыны булып Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган исемлегенә кертелгән дәүләт яисә территория тора торган (алга таба – офшор компанияләр) чит ил юридик заты булып саналмый, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләрнең турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аша) катнашу өлеше тулаем алганда 25 проценттан артып киткән россия юридик заты булып саналмый (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса). Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләгәндә, офшор компанияләренең Россия Федерациясендә оештырылган сатуларда акцияләре әйләнештә булган гавами акционер җәмгыятьләр капиталында турыдан-туры һәм (яисә) читләтеп катнашуы (шул исәптән халыкара компания статусы белән),шулай ук офшор компанияләренең күрсәтелгән гавами акционер җәмгыятьләр капиталында катнашу аша гамәлгә ашырылган башка Россия юридик затлары капиталында читләтеп катнашуы исәпкә алынмый;

Экстремистлык эшчәнлегенә яисә террорчылыкка катнашы булулары турында белешмәләре булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО Уставының VII бүлегендә, БМО Иминлек советында яисә БМО Иминлек Советының махсус төзелгән карарларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында төзелә торган вәкаләтләрдә булмый, террорчылык оешмалары һәм террористлар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә юк;

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының башка норматив хокукый актлары нигезендә әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан акча алмый;

«Чит ил йогынтысындагы затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып саналмый;

сайлап алуда катнашучының бердәм салым хисабында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы юк яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

сайлап алуда катнашучының Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетына бүтән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча срогы чыккан (җайга салынмаган) башка бурычы юк.

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тапшырыла торган гариза турында мәгълүматны, әлеге гаризадагы мәгълүматны һәм шәхси белешмәләрне сайлап алуга, шулай ук эшкәртүгә бәйле башка мәгълүматны (физик зат өчен) риза;

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибендә күрсәтелгән документлар исемлеген кушып бирәм.

__________ ____________________________________________

(имза) (сайлап алуда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)

«___»_____________, 2024 ел

Мөһер (булган очракта)

«Раслыйм»
Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе
__________ ____________________________________
(имза)
«____»_____________________, 20___ ел

«Килешенгән»
Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Кукмара районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы
_________ ____________________________________
(имза)
«____»_____________________, 20___ ел

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең _______ елның ______________ ______ номерлы карары белән расланган 2024 финанс елында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан 2024 һәм 2025 финанс елларында сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибенә
2 нче кушымта

## Өстәлгән бәягә салым түләү чыгымнарын киметеп, сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен каплауга 2024 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмәсе

_____________________________________________________ ИНН _________________________

(субсидия алучының исеме)

| №т/б | Атамасы | Факттагы урнашу урынының адресы | ИНН | Сатып алынган сөт юнәлешендәге нәселле таналар саны, баш | Сөт юнәлешендәге нәселле таналар бәясе һәм терлек хакыннан чыгып процентларда субсидия суммасы, НДСны исәпкә алмыйча, сум | | 1 башка субсидия ставкасы, сум (сатып алынган хайваннар хакының 60 процентыннан артыграк түгел) | Сатып алынган сөт юнәлешендәге нәселле таналарга 1 башка ставка буенча исәпләнгән субсидия, сум, (гр.5 х гр.8) | Сатып алынган сөт юнәлешендә нәселле таналар өчен субсидиянең иң чик ставкасы, 1 башка, сум | 1 башка чик ставка буенча исәпләнгән суммадан артмаган түләүгә субсидия, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Бәясе, сум | Процент | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| | | | | | | | | | | |

Мәгълүматларның дөреслеген раслыйбыз:

________________ ______________________________________ ____________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

(имза)
Мөһер

«Раслыйм»
Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе
___________ ________________________________________
(имза)
«____»______________________, 20___ ел

«Килешенгән»
Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Кукмара районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы
__________ ________________________________________
(имза)
«____»______________________, 20___ ел

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең _______ елның _______________ ______ номерлы карары белән расланган 2024 финанс елында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан 2024 һәм 2025 финанс елларында сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибенә
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы буенча сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын карау нәтиҗәләре турында
Реестр

| №т/б | Сайлап алуда катнашучы исеме | ИНН | Факттагы урнашу урыны адресы ________________________________________ ________________________________________ ____________________ (торак пункт, урам, йорт) | Гаризаны кабул итү датасы һәм вакыты (сәгать, минут) | Кире кагылган гаризалар (субсидияләүдән баш тартуны нигезләү (Тәртипнең конкрет пунктына туры килмәвен күрсәтергә)) | Сайлап алуда җиңүчеләргә бирелә торган субсидия күләме, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1 | | | | | | |
| 2 | | | | | | |
| 3 | | | | | | |
| 4 | | | | | | |
| | Барлыгы | х | х | х | х | |

______________________ (имза)

________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

______________________ (имза)

________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

Мөһер

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2024 елның 09 декабрендәге 703 номерлы карары белән расланган 2024 финанс елында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан 2024 һәм 2025 финанс елларында сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибенә 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирү турында ____ номерлы КИЛЕШҮ

Кукмара ш. «__» _________, 2024 ел

Бер яктан Нигезләмә нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, җитәкчесе Гарифуллин Азат Харис улы исеменнән (алга таба Башкарма комитет дип аталучы) һәм ______________________ (алга таба – субсидия алучы дип аталучы) ____________________________ исеменнән, ___________________ нигезендә эш итүче, икенче яктан (алга таба уртак телгә алганда Яклар дип аталучы), түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр.

1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешүнең предметы булып 2024 финанс елында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), эшчәнлеген бер календарь елдан кимрәк башкаручы, милек рәвешләренә карамастан, агросәнәгать комплексы оешмаларына 2024 һәм 2025 финанс елларында сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә, өстәлгән бәягә салым түләү чыгымнарын киметеп субсидияләр (текстта алга таба – субсидия) бирү тора.
1.2. Субсидия Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең (алга таба – Башкарма комитет) «2024 – 2026 елларга Кукмара муниципаль районы авыл хуҗалыгын үстерү» район муниципаль программасын раслау турында» 2024 елның 03 декабрендәге 695 номерлы карары белән расланган «2024 – 2026 елларга Кукмара муниципаль районы авыл хуҗалыгын үстерү» район муниципаль программасы кысаларында бирелә.
1.3. Субсидия бирү билгеләнгән тәртиптә бюджет акчаларын баш бүлүчегә –әлеге Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет акчаларын алучы буларак Башкарма комитетка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет

йөкләмәләре лимитлары чикләрендә сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.
1.4. Әлеге Килешү кысаларында Башкарма комитет акчаларын Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы (алга таба текст буенча – Финанс-бюджет палатасы) бүлә.

## 2. Субсидия бирү шартлары

2.1. Субсидия алучы, гариза бирү датасыннан да соңга калмыйча, сатып алына торган сөт юнәлешендәге нәселле таналар хакының кимендә 40 процентын үз акчалары исәбеннән түли.

2.2. Сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидия ставкасы сатып алу бәясенең 60 проценты исәбеннән, ләкин бер башка исәпләгәндә 75,0 мең сумнан артык булмаган күләмдә бирелә.

2.3. Сатып алына торган сөт юнәлешендәге нәселле таналар өчен уңышлы орлыкландыру яше 16 айдан да артмаска тиеш.

2.4. Субсидия алучы аңа карата Башкарма комитет тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерүне, шулай ук муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268 һәм 269 статьялары нигезендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга риза.

2.5. Алынган субсидия акчаларын, сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алганда Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә башкарыла торган операцияләрдән тыш, чит ил валютасын сатып алуга тоту тыела.

## 3. Субсидия бирү һәм күчерү тәртибе<br>Субсидия бирү нәтиҗәсе

3.1. 2024 елда субсидия алучыга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган максатчан субсидиянең күләме _____________ (_______________________) сум 00 тиен.
3.2. Башкарма комитет субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидия алучы тарафыннан ачылган исәп-хисап счетына акча күчерә.
3.3. Субсидия алучы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирелгән сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алу чыгымнарын Татарстан Республикасы бюджетыннан каплауга гариза бирергә хокуклы түгел.
3.4. Субсидия бирү нәтиҗәсе:
а) сатып алу датасына, субсидияләрдән файдаланып сатып алынган сөт юнәлешендәге нәселле таналар саны;
б) 2025 елның 31 декабренә эре мөгезле терлекләрнең маточный баш санын саклап калуны тәэмин итү, 2024 елның 1 гыйнварына булган мөгезле терлекнең баш санына карата.

Субсидиядән файдаланып сатып алынган сөт юнәлешендәге токымлы таналарның баш саны 2024 елның 1 гыйнварына булган маточный мөгезле эре терлекләрнең баш санынннан күбрәк булган очракта, 2025 елның 31 декабренә маточный мөгезле эре терлекләрнең баш саны сатып алынган сөт юнәлешендәге токымлы таналар башыннан кимрәк булмаска тиеш;

4. Якларның үзара хезмәттәшлеге

4.1. Башкарма комитетның бурычы:
4.1.1. Субсидия алучыга әлеге Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү шартлары тәртибендә һәм үтәп Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирүне тәэмин итәргә.
4.1.2. Субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм әлеге Килешүдә каралган башка йөкләмәләрне үтәвен тикшереп торырга.
4.1.3. Субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен үтәвен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә күрсәтелгән хисап бирелгән көннән алып 60 эш көненнән артмаган вакытта тикшерүне гамәлгә ашырырга. Муниципаль финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.
4.1.4. Бирелгән субсидиянең максатчан кулланылышын Россия Федерациясе законнары нигезендә Финанс-бюджет палатасы белән берлектә тикшереп торырга.
4.1.5. Субсидияне максатчан тотуны раслый торган документларны тикшерергә.
4.1.6. Субсидия алучыга әлеге Килешүне үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатьне алган көннән алып 30 эш көне эчендә аңлатмалар җибәрергә.
4.1.7. Татарстан Республикасы бюджет законнарында һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне гамәлгә ашырырга.
4.2. Район башкарма комитеты хокуклы:
4.2.1. Субсидия алучыдан субсидия алучының килешүдә каралган шартларны һәм башка йөкләмәләрне үтәвен тикшереп тору өчен кирәкле документлар һәм материаллар, шул исәптән субсидия бирү шартларын үтәүгә бәйле беренчел документлар соратып алырга.
4.2.2. Килешүнең яңа шартларын килештерү шарты белән субсидия алучы белән килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзергә – яңа шартлар буенча килешүгә ирешмәгәндә, Башкарма комитетка бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган киметелгән очракта.
4.2.3. Субсидия алучы белән юридик зат булган субсидия алучыны субсидия алучыны, килешүдә хокук варисы булган юридик затны күрсәтеп, йөкләмәдә затны алыштыру өлешендә берләштерү, кушу яисә үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп оештырган шартта килешүгә өстәмә килешү төзергә.
4.2.4 «Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында» 2003 елның 11 июнендәге 74-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә үз хокукларын башка гражданга тапшыручы, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 23 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацы нигезендә крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы буларак эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси эшмәкәр булган субсидия алучының субсидия алучының эшчәнлеге туктатылган очракта, килешүдә хокук варисы булган башка затны күрсәтеп, йөкләмәдә затны алыштыру өлешендә үзгәрешләр кертү юлы белән субсидия алучы белән Килешүгә өстәмә килешү төзергә.

4.2.5. Субсидия алучыдан әлеге Килешүнең 4.3.5 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат алган көннән соң 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы белән килештереп, бюджет законнары нигезендә субсидия алучының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган калган өлешен тотуга ихтыяҗы булу-булмавы турында карар кабул итәргә. Башкарма комитет субсидия алучының агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калган өлешен тотуга ихтыяҗы булу турында карар кабул иткән очракта, Башкарма комитет белән субсидия алучы арасында мондый карар кабул ителгән көннән алып календарь көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә өстәмә килешү төзелә.
4.2.6. Субсидия акчаларын килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап алган көннән алып календарь көннәрдә исәпләнә торган 60 көн эчендә кире кайтару турында, вакытын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп хәбәрнамә җибәрергә, почта аша аны тапшыру турында хәбәрнамә белән.
4.2.7. Татарстан Республикасы бюджет законнарында һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.
4.3. Субсидия алучы йөкләмә ала:
4.3.1. Хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 числосыннан да соңга калмыйча, сөт юнәлешендә нәселле таналар сатып алу чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнар турында хисапны, ә еллык хисапны әлеге Килешүнең 1 кушымтасы нигезендәге форма буенча – 2025 елның 1 февраленнән, 2026 елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Финанс-бюджет палатасына илтеп тапшырырга.
4.3.2. Сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга агросәнәгать комплексы оешмаларының авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең чыгымнар өлешен каплауга субсидия нәтиҗәсенә ирешү турында һәм аңа ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр турында 3.4 пунктының "а" "б", "в" пунктчалары нигезендә 2025 елның 1 февраленнән һәм 2026 елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча Финанс-бюджет палатасына әлеге Килешүнең 2 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча һәм түбәндәге документларны теркәп хисап илтеп тапшырырга:

- Башкарма комитет тарафыннан расланган форма буенча нәсел таныклыклары (сертификатлар) реестры һәм сатып алынган сөт юнәлешендәге нәселле таналар өчен нәсел таныклыклары (сертификатлар) күчермәсе;

- сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алган көннән 2025 елның 31 декабрен дә кертеп, фермада терлек һәм кош-корт движениесе турында хуҗалык эчендәге айлык хисап күчермәсе;

- сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуныраслый торган накладной яисә көтү ведомосте күчермәсе;

- сатып алынган сөт юнәлешендәге нәселле таналар өчен «Меркурий» дәүләт мәгълүмат системасыннан алынган, бергә теркәлә торган ветеринария документларының (ветеринария таныклыгы, ветеринария белешмәсе) күчермәсе;

- субсидия алучының Татарстан Республикасы «Кукмара район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан бирелгән терлекләрне карантиннан чыгару актының күчермәсе;

- сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуны һәм түләүне раслый торган банк өземтәсенең һәм түләү йөкләмәсенең (аванс түләвен дә кертеп), накладной яисә көтү ведомостенең күчермәсе;

Тапшырылган документларның күчермәләре субсидия алучы тарафыннан таныклана.

4.3.3. Субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм әлеге Килешүдә каралган башка йөкләмәләрне үтәвен тикшереп торуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм материалларны, шул исәптән, субсидия алучының субсидия бирү шартларын үтәвенә бәйле бухгалтерлык исәбе һәм беренчел документлар белешмәләрен Башкарма комитетка тапшыруны тәэмин итәргә.
4.3.4. Агымдагы финанс елының беренче 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты кеременә 2025 елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлешләрен кайтарырга, моңа күрсәтелгән акчаларга ихтыяҗ булу-булмавы турында Финанс-бюджет палатасы белән килештереп Башкарма комитет тарафыннан карар кабул ителгән очраклар керми.
4.3.5. Хисап финанс елында файдаланылмаган акчаларны әлеге Килешүнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатларга куллану ихтыяҗы булган очракта, субсидия алучы, хисап елыннан соң килә торган агымдагы финанс елының 5 эш көненнән дә соңга калмыйча Башкарма комитетка, мондый ихтыяҗны нигезләп, мәгълүмат тапшырырга бурычлы.
4.3.6. Татарстан Республикасы бюджет законнарында һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне гамәлгә ашырырга.
4.4. Алучы хокуклы:
4.4.1. Әлеге Килешүнең үтәлешенә бәйле рәвештә район Башкарма комитетына аңлатмалар сорап мөрәҗәгать итәргә.
4.4.2. Татарстан Республикасы бюджет законнарында һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

## 5. Якларның җаваплылыгы

5.1 Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык тота.
5.2 Бирелгән субсидия Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты керемена Башкарма комитетның тиешле хәбәрнамәсен алган көннән календарь көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш:

- тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия биргәндә билгеләнгән шартларны, шул исәптән Башкарма комитет һәм муниципаль финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартларны бозу ачыкланган очракларда;
- әгәр субсидия алучы субсидия бирү нәтиҗәсенең килешүдә билгеләнгән күрсәткечләренә ирешмәгән очракта, субсидия алучы субсидия акчаларын формула буенча билгеләнә торган күләмдә (Vвозврат) кире кайтара:

$$V_{возврата} = (V_{субсидии} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

Vсубсидия – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;
k – түбәндәге формула буенча билгеләнә торган, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:
T – субсидия алучының хисап датасына субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән күрсәткече;
S – субсидия алучыга килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең планлы күрсәткече.
Субсидия акчаларын кире кайтару күләмен исәпләгәндә, коэффициентның субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган уңай күрсәткечләре генә файдаланыла.
5.3 Субсидия 5.2 пунктында күрсәтелгән вакытта, субсидия түләүгә бирелгән акчаларның максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмавы һәм (яисә) дөрес булмаган хисап тапшыру һәм (яисә) аны тапшырмау, һәм (яисә) әлеге килешү шартлары бозылуы ачыкланган очракта, Кукмара муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.
5.4 Форс-мажор хәлләр килеп чыккан очракта, Яклар әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә. Форс-мажор хәлләр дигәндә, акыллы саклык белән эш итүче Яклар, үзләренә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында, үз бурычларын тиешенчә үти алмый торган хәлләрнең килеп чыгуы аңлашыла, аерым алганда, мондый хәлләргә килешү буенча йөкләмәләрне тиешенчә үтәргә мөмкинлек бирми торган хәрби гамәлләр, стихияле бәла-казалар керә. Форс-мажор хәлләр туганда, Яклар күрсәтелгән хәлләр туу турында өч көн эчендә бер-берсенә хәбәр итәргә тиеш.
5.5. Субсидия алучы субсидияне максатчан файдаланган өчен, шулай ук әлеге Килешү нигезендә хисапларның дөреслеге, тулылыгы һәм Финанс-бюджет палатасына вакытында тапшырылуы өчен җаваплы.
5.6. Алынган субсидияне тотуга кагылышлы документлар тапшырылмаган очракта, субсидияне максатчан тотмаган очракта, шулай ук дөрес булмаган йә ялган документлар бирелгән очракта, Башкарма комитет субсидия алучыга Килешүне вакытыннан алда өзү турында хәбәрнамә җибәрү юлы белән Килешүне берьяклы тәртиптә өзәргә хокуклы.
5.7. Килешүнең 4.2.6. пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне алганнан соң, субсидия алучы алынган субсидия суммасын Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты кеременә шушы килешүнең 4.2.6 пункты һәм 5 бүлеге нигезендә кире кайтарырга тиеш.
5.8. Әлеге килешүнең 4.2.6. пунктында күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты керемenә ирекле кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә 30 көн эчендә Башкарма комитет тарафыннан мәҗбүри рәвештә түләтелергә тиеш.

## 6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Яклар арасында әлеге Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган бәхәсләр, мөмкин булганча, беркетмәләр яисә башка документлар рәсмиләштереп сөйләшүләр уздыру юлы белән хәл ителә. Килешүгә ирешмәгән очракта, Яклар арасындагы бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.
6.2. Әлеге Килешү һәр Як исеменнән эш итәргә хокуклы затлар тарафыннан имзаланган датадан үз көченә керә һәм әлеге Килешү буенча 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була. Килешүне гамәлдән чыгару Якларны әлеге Килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәүдән азат итми.
6.3. Килешүгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр язма рәвештә төзелгән һәм Якларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган очракта гына гамәлдә була.
6.4. Килешү белән җайга салынмаган мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җайга салына.
6.5. Килешү Якларның килешүе, суд карары буенча яисә Килешүдә каралган хәлләр туган очракта вакытыннан алда өзелергә мөмкин.
6.6. Килешү буенча барлык бәхәсләр Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты урнашкан урын буенча судка мөрәҗәгать итеп хәл ителә.
6.7. Килешүгә кул куеп, субсидия алучы Башкарма комитет һәм муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүгә ризалыгын белдерә.
6.8. Килешү тигез юридик көчкә ия 2 нөсхәдә төзелде.

7. Якларның адреслары һәм реквизитлары:

| | |
|---|---|
| Кукмара муниципаль районы<br>Башкарма комитеты<br>422110, Кукмара ш., Ленин ур.,15<br>КБК 60520405099050000150<br>Р/счет 03100643000000011100<br>Кор.счет 40102810445370000079<br>РОССИЯ БАНКЫНЫҢ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ БАНК БҮЛЕГЕ//Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе Казан шәһәре<br>БИК 019205400<br>Алучы: Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе (Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы) ИНН 1623008271 КПП 162301001 Лиц счет 04113000270<br>ОКТМО: 92633000 | ___________________________________<br>___________________________________<br>___________________________________<br>Адрес_____________________________<br>___________________________________<br>___________________________________<br>___________________________________<br>ИНН ______________________________<br>КПП<br>_________________________________ |
| Җитәкче | ___________________________ |
| _________________А.Х. Гарифуллин | ________________ /_____________/ |

2024 елның ______ _________________ _____ номерлы
Килешүгә 1 нче кушымта.

202____ елның «___» ________ сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнар турында хисап

Алучының исеме _______________________________________________________________________
Ешлык: квартал, еллык
Үлчәү берәмлеге: сум

| Күрсәткеч исеме | Үсә барган йомгак суммасы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Субсидиянең калган өлеше ел башына, барлыгы: | |
| шул исәптән: расланган ихтыяҗ | |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетына кайтарылырга тиешле, барлыгы: | |
| Акча кергән, барлыгы: | |
| шул исәптән: Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан | |
| Чыгымнар буенча түләүләр, барлыгы: | |
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетына кайтарылган, барлыгы: | |
| шул исәптән: максатчан билгеләнеше буенча тотылмаган | |
| штраф санкцияләрен куллану нәтиҗәсендә | |
| Хисап чоры ахырына субсидиянең калган өлеше, барлыгы: | |
| шул исәптән: шул ук максатларга кулланырга таләп ителә | |
| кире кайтарылырга тиеш | |

Алучы ___________ __________ _________________________

(вазыйфасы) (имза) (имзаның расшифровкасы)

Башкаручы _____________________________ _____________ _________________

(вазыйфасы) (Ф.И.А.) (телефон)

«___» __________ 20__ ел

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты

Җитәкче

________________А.Х. Гарифуллин

_______________________________________
_______________________________________
_______________________________________

_______________________________________

_______________ _____________________

2024 елның ______ _________________ _____ номерлы Килешүгә 2 нче кушымта.

Сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең чыгымнар өлешен каплауга субсидия нәтиҗәсенә ирешү турында һәм аңа ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр турында ХИСАП, ______________ ел өчен

_____________________________________________________________________________________

(субсидия алучыны, муниципаль берәмлекнең исеме)

| №т/б | Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткечнең пландагы кыйммәте | Күрсәткечнең факттагы кыйммәте |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Субсидия бирү нәтиҗәсе | | | | |
| 1. | Сатып алынган сөтчелек юнәлешендәге эре мөгезле таналарның баш саны | Баш | | |

Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе – субсидия алучы җитәкчесе (шәхси ярдәмче хуҗалык җитәкчесе) _____________ _____________________

(имза) (инициаллар, фамилия)

Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче – субсидия алучының баш бухгалтеры, бухгалтеры (булган очракта)

_____________ _____________________

(имза) (инициаллар, фамилия)

М.У. (мөһер булганда)

_____________________________________________________________________________________

Хисап тикшерелде:

Субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткече ____ процент тәшкил итә.

_______________________________________ ____________________ _________________________

(вазыйфасы) (имза) (инициаллар, фамилия)

____ «________________ 20___ ел

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты

_________________________________________

_________________________________________

_________________________________________

Җитәкче

_________________________________________

_________________А.Х. Гарифуллин

________________ _______________________